ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» апреля 2026 ел № 95

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 августындагы 282 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 29 маендагы 124-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 августындагы 282 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турындагы нигезләмәне: «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру комиссиясе» дип атарга.

1.2. Карар преамбуласыннан түбәндәгеләрне төшереп калдырырга: «Заказлаучылар (подрядчылар, башкаручылар) өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыручы муниципаль заказчыларның заказчылар (подрядчылар, башкаручылар) өчен товарлар, эшләр сатып алуга вәкаләтле муниципаль орган белән үзара эшчәнлеге тәртибе турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карары белән.

1.3. Кушымтаның 1.2.1 пунктындагы 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Заказ бирүче - дәүләт яки муниципаль заказчы, яки "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1, 2.1, 4, 4.3 һәм 4.4 өлешләре нигезендә бюджет яисә муниципаль унитар учреждение, дәүләт яки муниципаль унитар предприятие сатып алуларны гамәлгә ашыручы яки башка юридик зат".

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәриповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**